| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**04.07.2022** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1637** |
|---|---|---|

«Коммуналь хуҗалык» муниципаль унитар предприятиесе күрсәтә торган башка кулланучылар өчен транспорт хезмәтләре тарифларын раслау турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 17 статьясындагы 1 пункты 4 пунктчасы һәм Зеленодольск муниципаль районының 2022 елның 24 июнендәге муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр хезмәтләренә тарифларны (бәяләрне) карау комиссиясе карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Коммуналь хуҗалык» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган башка кулланучылар өчен транспорт хезмәтләренә тарифларны кушымта нигезендә расларга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 3 сентябрендәге 1628 номерлы «Коммуналь хуҗалык» муниципаль унитар предприятиесе күрсәтә торган башка кулланучылар өчен транспорт хезмәтләре тарифларын раслау турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (www.zelenodolsk.tatarstan.ru) “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче вазыйфасын башкаручы А.В. Старостин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның 04 июлендәге 1637 номерлы
карарына
кушымта

**«Коммуналь хуҗалык» муниципаль унитар предприятиесе күрсәтә торган башка кулланучылар өчен транспорт хезмәтләренә тарифлар һәм хезмәтләр исемлеге**

| Машиналарның исеме | Машина-сәгать, бәясе сум. |
|---|---|
| Автогрейдер | 2 500 |
| МТЗ базасында урып-җыю машинасы | 1 500 |
| МТЗ базасында асылмалы җайланма (ваклагыч) белән урып-җыю машинасы | 2 000 |
| Камаз базасында катнаш юл машинасы (механикалаштырылган җыештыру) | 2 500 |
| Камаз базасында катнаш юл машинасы (су китерү) | 2 000 |
| Амкадор 333В | 2 000 |
| Камаз 65115 | 1 500 |
| Камаз 45143 | 1 500 |
| КО 316Б (пылесос) | 4 000 |
| МК 1500 (пылесос) | 4 000 |